РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАМАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАРАМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д 8, с.Карамалы,
Азнакаевский муниципальный район 423301

Үзәк ур., 8 нче йорт, Карамалы авылы,
Азнакай муниципаль районы, 423301

Тел./факс(885592)4-56-42; E-mail:Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» октябрь 2020 ел № 18

Татарстан Республикасы, Азнакай
муниципаль районы, Октябрь-Бүләк авылы ,
Үзәк ур., 11 А адресы буенча урнашкан
шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән
яки капиталь төзелеш объектыннан файдалану төренә
рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларын
билгеләү турында

Карамалы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең фикерен һәм мәнфәгатьләрен ачыклау һәм исәпкә алу максатыннан, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалану төренә рөхсәт бирү сораулары буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Карамалы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә:
1.1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Октябрь-Бүләк, Үзәк ур., 25 йорт адресы буенча урнашакан - гомуми мәйданы 150 кв. метрдан артмаган беренче кирәкле товарлар кибетләре - индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1), 16:02:210102:194кадастр номерлы, мәйданы 19 кв. м булган җир кишәрлегеннән һәм 16:026210102:166 кадастр номерлы мәйданы 40 кв.м булган җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалану төренә.

2. Билгеләргә:
- Карамалы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча ачык тыңлауларны оештыручыны;
- үткәрү вакыты-2020 елның «05» октябрь 2020 елның «12» октябренә кадәр-17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны-Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының

административ бинасы, Карамалы авылы, Үзәк урамы, 8 нче йорт;

- 2020 елның «12» октябренә кадәр фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Карамалы авылы, Үзәк урам, 8 нче йорт, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- 2020 елның «05» октябренә кадәр, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын, җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләре ияләренә, рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртүгә рөхсәт сорала торган җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан файдалану хокукына рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында хәбәрләр җибәрергә.;

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru//.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Ногманов А.Р.